СОВЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2021 г. Агрыз № 14-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының кайбер карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарга шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм индивидуаль торак төзелеше өчен милек буларак бирелә торган җир участокларының иң чик күләмнәре турында» 2006 елның 29 мартындагы 5-3 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм индивидуаль торак төзелеше өчен милек буларак бирелә торган җир участокларының иң чик күләмнәре турында» 2006 елның 29 мартындагы 5-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 07 августындагы 49-11 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советыц «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм индивидуаль торак төзелеше өчен милек буларак бирелә торган җир участокларының иң чик күләмнәре турында» 2006 елның 29 мартындагы 5-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 29 июнендәге 10-11 номерлы карарлар.

2. Әлеге караны «Татмедиа» АҖ филиалының «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы вакытлы матбугат басмасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе А.Р. Вәлиев